| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.10.2025 ел

КАРАР
№ 31

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының
Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә
йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны көтүгә өстәмә таләпләрне раслау турында»гы 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары, Кече Лызи авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең сакланышын тәэмин итеп, йорт хайваннарын урамда йөртү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртергә рөхсәт ителгән урыннар:

- хуҗалар кулланылышында яки милегендә булган җир участоклары;

- торак секторларыннан читтә һәм торак булмаган биналар янында урнашкан гомуми куллану территорияләре.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Бу карар рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы Л.М.Михайлова